ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

« 29 » ноябрь 2016 ел № 1242

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 01 июлендәге 726 номерлы карары белән расланган “Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 1 июлендәге 726 номерлы карары белән расланган “Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” Арча муниципаль районы территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының "Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 27 июнендәге 3040/12 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга карата опека (попечительлек) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 27 июнендәге 3040/12 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 14 октябрендәге 2107/16 номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатыннан Арча район башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 01 июлендәге 726 номерлы карары белән расланган “Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында”гы 726 номерлы карары белән расланган “Россия Федерациясе

территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктта, 2 нче баганада, б пунктчада:

«соңгы 12 айда уртача хезмәт хакы вазыйфасын һәм күләмен күрсәтеп, эш урыныннан белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы гражданнар өчен - керемнәрне раслый торган башка документ (пенсионерлар өчен - пенсия таныклыгы күчермәләре, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнан белешмә)» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. б) «соңгы 12 айда уртача хезмәт хакы вазыйфасын һәм күләмен күрсәтеп, эш урыныннан белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен - керемнәрне раслый торган башка документ (пенсионерлар өчен - пенсия таныклыгы күчермәләре);»

2.6 пунктында, 2 нче багана, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан кирәкле документлар:

- яшәү урыныннан йорт (поквартир) китабыннан өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын йә, торак урынга милек хокукын, яшәү урыныннан финанс счеты күчермәсен раслый торган башка документ;

- гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы бәлә торып җинаять кылган өчен опекун булырга теләк белдергән гражданның булмавын раслаучы эчке эшләр органнары белешмәсе;

- мөрәҗәгать итүченең торак-конкүреш шартларын тикшерү акты;

- тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килә торган торак урыннарның (опека һәм попечительлек органы белгеченең мөрәҗәгать итүче белән торак бинага керү мөмкинлеген алдан килештереп) туры килүе турында белешмәләр) түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

« - соңгы 12 айда уртача хезмәт хакы вазыйфасын һәм күләмен күрсәтеп, эш урыныннан белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы гражданнар өчен - керемнәрне раслый торган башка документ (пенсионерлар өчен - пенсия таныклыгы күчермәсе).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла ".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин